**История моей семьи в годы Великой Отечественной войны**

**Сайфуллин Мухамадулла Сайфуллович**

**(1904-18.10.1988)**



Мое повествование основано на рассказах моих дедушки и бабушки и документах, представленных ниже. Сайфуллин Мухамадулла Сайфуллович - мой прадед по папиной линии. Он потерял отца старшего брата в раннем детстве и остался с матерью. Мой прадед был очень решительным, требовательным, строгим и суровым человеком. Мне кажется, что именно эти качества помогли ему пережить трудные времена и вернутся героем.

Мухамадулла родился в небольшой семье в деревне Исламбахты Ермекеевского района Республики Башкортостан. После смерти отца работал на богатых. Затем учился в местной школе 4 класса. В 1942 году был мобилизован в ряды Советской Армии. Участвовал в боях в составе 112-ой Башкирской Кавалерийской дивизии во главе Минигали Мингазовича Шаймуратова. Во время войны получил небольшие ранения рук. После демобилизации был тружеником колхоза «Яна юл» (Новая дорога). За участие в Великой Отечественной войне Мухамадулла был награжден следующими медалями: медаль «За отвагу», медаль «За взятие Варшавы» и другие. Фотографии этих наград представлены ниже. О войне мой прадед говорил неохотно и избегал этой темы. Мухамадулла пережил эти трудные годы и умер в старости от болезни в кругу семьи.

Мой прадед защищал свою Родину, семью, всех нас, стал частью одного из самых ужасных исторических событий. Возможно, если бы не он, то я бы сейчас не жил. Он – мой герой, моя память, которую я ценю и помню, как и вся моя семья.




Награды, полученный моим прадедом



# Исламбахтылылар — башкорт атлы дивизия составында

1941 елның 18 ноябрендә ВКП (б) Өлкә Комитеты һәм Башкорт АССР Халык Комиссарлары Советының утырышында Дәүләт оборонасы комитеты карарын хуплап, Башкортстаннан ике кавалерия дивизиясе төзү һәм матди яктан тәэмин итү өчен махсус комиссия оештырыла. 112нче Башкорт кавалерия дивизиясенә командир итеп Миңнегали Минһаҗ улы Шәйморатов билгеләнә.

Ярмәкәй районының Исламбахты авылында туып-үскән егермеләп якташым шушы дивизия составында сугыша. Аларның берничәсе турында Әхтәм Ихсанның "Чакма тояк атларда" (Уфа, 1995) китабыннан укып белергә була. Ә дивизиянең партия оешмасы секретаре Ибраһим Ислам улы Фәттахов белән фронтта очрашуы турында районыбызның элекке хәрби комиссары Әмир Насыйров район гәзитендә язып чыккан иде. Данлыклы авылдашым Фәттахов абый Миякә районының Илчегол авылыннан ("Большевик" колхозы) сугышка җибәрелгән Керчь кушаматлы ат белән сугыш юлларын бергә үтеп, аны туган колхозына алып кайтып тапшыра. Бу турыда беренчеләрдән булып Кадыйр Даян гәзиттә һәм журнал битләрендә (1946 ел) язып чыккан иде. Соңрак Әнвәр Бикчәнтәевның хикәяте, Таһир Таһировның хатирәләре, Сәрвәр Суринаның очерклы дөнья күрә. Ике телевизион фильмны да күрергә туры килгән иде: берсенең исеме "Жил-был конь", икенчесенеке "Тулпар атым — пар канатым". Фотороәсемнәрдән һәм мәкаләләрдән альбом төзеп, мәктәбебезнең музеена тапшырган идем.

Күптән түгел тагын бер уникаль табылдыкка тап булдым. Бәләбәй крайны өйрәнү музеенда саклаган бер фотографиядә 1944 елның мартында Башкортстан АССР Югары Советының юбилей сессиясендә Фәттахов котлау сүзе белән чыгыш ясый, Башкорт атлы дивизиясе сугышчыларыннан республикабыз хезмәтчәннәренә ялкынлы сәлам тапшыра, безнең егетләрнең батырлыклары, дивизиянең данлыклы хәрби юлы турында горурлык белән сөйли.

Октябрь революциясенең 25 еллыгы алдыннан дивизиягә Башкортстаннан делегация килә, яугирләргә бүләкләр тапшыралар, һәр бүләк эчендә хат та бар. Шундый бүләк, бигрәк тә туган яктан килгән бер яшь кызның хаты авылдашым Закир Вафинның күңеленә хуш килә һәм ул җавапны шигъри юллардан төзеп, делегация әгъзасы Сәйфи Кудашка тапшыра. Авылдашымның җавап хаты озакламый республика гәзите битендә дөнья күрә, анда шундый юллар бар:

**Сагынсаң да, иркәм,**
**ачуланма,**
**Мине түгел әле,**
**Җиңү көт.**

Закир агай үзенең бөтен гомерен балалар укытуга багышлады, бу изге эштән ул тик сугыш елларында гына аерылып торды. Ә фронтта ул дивизия штабы каршындагы элемтә эскадронында хезмәт итә, радист-телефонист кына түгел, разведчик, пулеметчы, артиллерияче дә була, якташыбызга күп кенә вакыт дивизия командиры Шәйморатовның пешекчесе дә булырга туры килә. Җиңү көнен Берлинда батарея командиры буларак каршылый һәм Рейхстаг стенасына үзенең фамилиясен язып калдыра.

Тагын бер авылдашым турында Сәгыйть Агиш "Поезд фронтка бара" дигән очеркында (февраль, 1943 ел) менә ничек язган иде: "Элекке юстиция халык комиссары, РСФСР Югары Советы депутаты Ибраһим Фәттахов сүз уңаенда үзенең коноводы Минһаҗевны сагынып искә ала. Кызык кеше ул минем Фәррах карт. Ярмәкәй районы, Исламбахты авылыныкы ул. Комиссия кайтарып җибәрергә теләгән, ә ул кайтмый, тарткалаша: "Нишләп мин сугышны ташлыйм?" — ди. Уйлап карагыз, аңа 47 яшь! Ә дәрт нинди үзендә!

Янә бер авылдашым Әһлетдин абый Таҗиев сугышны шулай ук Берлинда тәмамлый, башка бүләкләр арасында "Берлинны алган өчен" медале дә бар. Улы Алис Таҗиев миңа әтисенең яудашлары белән кумәкләп төшкән ике фоторәсемен тапшырды. Анда Әһлетдин абый белән янәшә икенче авылдашым — Сәйфуллин Мөхәммәдулла агай.

Сабакташым Сәлимә Әмирова (Харисова) әтисе Хәсән абый Харисов турында истәлек язып, миңа тапшырды, берничә фоторәсем белән мин аны мәктәбебезнең музеена тапшырачакмын.

Бөек Җиңүнең 60 еллыгы билгеләнгән елда берничә авылдашымны искә алып язып чыгуны үземнең изге бурычым дип санадым.

**Рифмир ГӘРӘЕВ.**
Ярмәкәй районы,
Исламбахты авылы.

Статья в газете о дивизии.

## АЛАР ДАНЫ МӘҢГЕЛЕК

Германия фашизмы белән сугыш көннән-көн бездән ерагая бара.Шушы бөек вакыйгаларның тере шаһитлары, анда катнашучылар сафы сирәгәннән сирәгәя бара.

Дистәләрчә еллар тарих битләренә керсә дә, Бөек Җиңу хакына уз гомерләрен биргән сугышчыларны хәтердән сызып ташлау мөмкин тугел.Туган илгә, уз халкына олы мәхәббәтне безгә мирас итеп калдырдылар.Фронтта илебез намусын, бәйсезлеген яклаучыларны , тылда «Барысы да фронт өчен, барысы да җиңу өчен!» дигән лозунг астында әшләучеләрне онытырга ярамый.

Шушы җиңу өчен безнең Ярмәкәй районыннан 4145 якташыбыз яу кырында башын салды, аларның исемнәре Истәлек китабына кертелде.

Исламбахты авылыннан да бөтен гаиләдән авылның иң кыю уллары белән кызлары-барлыгы 252 кеше фронтка киткән.Шуларның 127 се яу кырында ятып калган.

Документ, в котором написаны мотивирующие слова, количество умерших и ушедших на фронт (4145 солдат погибли с Ермекеевского района, 252 человека ушли на фронт из деревни Исламбахты, из них 127 погибли).